ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# «Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәреш кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

«Торак шартларын яхшыртуда яшь гаиләләргә дәүләт ярдәме турында» 1999 елның 21 октябрендәге 2443 номерлы Татарстан Республикасы Законының 1 статьясындагы өченче абзацына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 11; 2001, № 7 – 8; 2005, № 1 (I өлеш); 2011, № 12 (I өлеш); 2013, № 11 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыелмасы, 2017, № 52 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«яшь гаилә – 35 яшькә кадәрге (бу яшьне дә кертеп) Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә никахта торучы, шул исәптән бала (балалар) тәрбияләүче затлар, йә баланың (балаларның) бердәнбер әтисе яки әнисе (уллыкка алучысы) булып торучы зат;».

**2 статья**

Әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр торак шартларын яхшыртуда дәүләт ярдәме күрсәтү өчен исәпкә куелган гаиләләр әлеге Закон үз көченә кергән көнгә кадәр билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда мондый дәүләт ярдәмен алу хокукын саклыйлар.

**3 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 05 май
№ 28-ТРЗ